**СОВЕТ**
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**« 20 » апреля 2026 ел** **№ 14**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 2023 елның 29 ноябрендәге 104 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2024 елның 10 сентябрендәге 125 номерлы, 2025 елның 26 ноябрендәге 8 номерлы үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 29.11.2023 елның 29 ноябрендәге 104 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2024 елның 10 сентябрендәге 125 номерлы, 2025 елның 26 ноябрендәге 8 номерлы үзгәрешләр белән):

1.1. 2нче пунктта:

1.1.1. 5 пунктчаны 7 пунктча дип санарга;

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) түбәндәгегә карата 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;»;

1.1.3. түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) түбәндәгегә карата 2,5 процент:

- проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;»;

1.2. 4нче пунктта:

1.2.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган физик затлар (мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);»;

1.2.2. өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрге балалар, әлеге пунктның 4.1 бүлегендә күрсәтелгән физик затлар.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609012621